**Эшне үтәде: Казан шәһәре 16 нче татар-инглиз гимназиянең татар теле һәм әдәбияты укытучысы Мортазина Алия Фоат кызы.**

## "Сүз басымы" темасын өйрәнү үзенчәлекләре

Замана укытучы алдына һәрьяктан үскән камил шәхес тәрбияләү бурычын куя икән, димәк, аның укучысы матур, эзлекле итеп сөйләшә, аралаша да белергә, кыскасы, сөйләм культурасына ия булырга тиеш.

Сөйләм аһәңле, үтемле һәм аңлашлы булсын өчен, һәр сүздә куелырга тиешле басым үз урынында булырга тиеш. Бары тик шул очракта гына сөйләм яңгырашына ирешеп була.

Беркемгә дә сер түгел: замана укучысының күп өлеше китап укымый, татар телендәге тапшыруларны карамый, милли матбугат белән кызыксынмый. Ә гаиләдә әби – бабасы, әти – әнисе, туган – тумачалары белән "вата – җимерә" татарча сөйләшүчеләрне һич аңлап булмый.Мондый шартларда, табигый, укучыны матур итеп сөйләшергә, фикер төгәллегенә, басымны дөрес итеп куярга өйрәтү эше укытучы җилкәсенә төшә. Рус телендә белем бирүче мәктәп шартларында татар теле фәненә бирелгән сәгатьләрнең аз булуын исәпкә алсаң, укытучыга җиң сызганып эшләргә һәм дәрестә һәр минутны рациональ кулланырга тиешлеге көн кебек ачык була.

"Басым – сүзнең җаны ул",- дигән б.э.к. IV гасырда яшәүче бөек рим грамматигы Диомед. Бу фикер белән килешми һич мөмкин түгел, чөнки басымын югалткан сүз үзенең мөстәкыйльлеген югалта һәм, теге яки бу сүзгә ияреп, кушымчага әйләнә. Мәсәлән, төрки телләрдәге торур фигыле,әкренләп –дыр кушымчасына әйләнеп, соңыннан бөтенләй юкка чыга.

Сүз (иҗек) басымы – сүздәге бер иҗекнең башкаларыннан аерылып торуы. Иҗек басымының төрле функцияләре күзәтелә:

- ул сүзне оештыра һәм сүз чиген аера
- мәгънәне аера ( ба̀рсын – барсы̀н )
- яңа сүз ясый ( тә̀мам – тәма̀м)
- сүз һәм җөмләне бәйли ( аныклау, күтәрү интонациясендә тон хәрәкәте)
- ритм барлыкка китерә

Сүз басымы, гадәттә, бер иҗеккә генә төшә. Ике тамыр кушылып, иҗекләр артып китсә, өстәмә басым да сакланырга мөмкин.

Һәрбер телдә басым төрлечә кулланыла, төрле иҗекләргә төшә. Төрки телләрдә, аерым алганда, татар телендә басым соңгы иҗеккә омтыла, әмма аннан чыгармалар да бар.

Рус мәктәбе шартларында татар теле укытканда укучылар тарафыннан авыр үзләштерелә торган темаларның берсе – "Сүзләрдә яки төрле сүз төркемнәрендә басымның урыны" темасы. Минем фикеремчә, әлеге теманы үзләштерү өчен программада сәгатьләр саны бик аз күләмдә каралган. Аерым алганда, 5 сыйныфта (татар төркемнәре, дәреслек авторлары – Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова) "Сүз басымы" дигән тема бирелгән. Басым

төшенчәсенә бәяләмә бирелгәннән соң, татар телендә басымның соңгы иҗеккә төшүе бик төгәл күрсәтелгән. Шулай ук IIзат берлек һәм күплек саннардагы боерык фигыльләрдә басымның беренче иҗеккә, юклык кушымчасы ( -ма, - мә) ялганган фигыльләрдә басымның юклык кушымчасы алдына төшүе ( карàма, сорàма, сөйлə̀мә), хәзерге заман хикәя фигыльләрдә басымның зат – сан кушымчасы алдына төшүе ( барàсың, күрə̀сең), -ган, -гән, -кан, -кән кушымчалы үткән заман хикәя фигыльләрдә; - ачак, -әчәк, -ячак, -ячәк кушымчалы киләчәк заман хикәя фигыльләрдә басымның зат – сан кушымчалары алдына төшүе: баргàнмын, киткə̀нсең, барачàкмын, китәчə̀ксең, - ды, -де, -ты, -те кушымчалы үткән заман хикәя фигыльләрдә басымның зат –сан кушымчаларына төшүе ( барды̀гыз,сүттѐләр, көттѐләр, бакты̀лар) күрсәтелә.

Шулай ук сорау алмашлыкларында басымның беренче иҗеккә төшүе искәртелә: кѐмдер, нѝчек, кàйда, кàйчан? Әлбәттә, әлеге дәреслектә күнегүләр дә бик уңышлы сайланылып, укучыларның танып белү мөстәкыйльлеген үстерүгә юнәлтелгәннәр.

7 сыйныф укучылары өчен язылган дәреслектә (татар төркемнәре, авторлары – Р.Ә.Асылгәрәева, М.З.Зиннәтовалар) “Боерык фигыльләрдә басым һәм интонация” темасын өйрәнгәндә мәкаль һәм әйтемнәр, төрле күнегүләр ярдәмендә II зат берлек һәм күплек саннарында басымның беренче иҗеккә төшүе искәртелә.

10 сыйныфта (татар төркеме, авторлары – Р.С.Абдуллина, М.Шәйхиевалар) “Сүзне оештыручы иҗек басымы” темасында төрле сүз төркемнәрендә басымның урыны турында тирән мәгълүмат бирелә. Шул мәгълүматны кулланып, мин үземнең укучыларым өчен “Исеңдә тот! Боларны онытма!” дип исемләнгән терәк схемалар ясадым. Һәр дәрестә әлеге терәк кагыйдәләргә мөрәҗәгать иткән укучы, әлбәттә, басым турындагы барлык кагыйдәләрне үзләштерә, исендә тота һәм гамәли куллана ала башлый.Тик әлеге терәк схеманы мин укучыларыма 5 нче сыйныфтан ук тәкъдим итәм, һәр дәрестә теге яки бу сүз төркемен өйрәнгәндә, басымны һәрдаим искә төшертергә тырышам. Шул рәвешле, укучылар шушы кагыйдәләрне күңелдән өйрәнеп бетерәләр һәм гамәли куллана алалар. Терәк схемаларны шул рәвештә ясарга мөмкин:

- Исемнәрдә басым соңгы иҗеккә төшә (уты̀н – утыннàр – утыннаргà)
- Исемнәрдә хәбәрлек кушымчасы булса, басым хәбәрлек кушымчасы алдындагы иҗеккә төшә (балыкчы̀ – балыкчы̀мын, укытучы̀ – укытучы̀мын)
- Алынма сүзләрдә татар телендәге кушымчалар ялганган саен, басым соңгы иҗеккә күчә бара (портфѐль – порфелѐ - портфеленѐң)
- Сыйфат басымны соңгы иҗеккә кабул итә (кызы̀л, кызы̀к, төчкелтѐм, кызгы̀лт, ямьлѐ)
- Сыйфатлар көчәйткеч кисәкчәләрне кабул итсәләр, басым беренче иҗеккә төшә (ѝң матур, я̀мь – яшел, кàп – кара, шо̀п – шома)

- Саннар шулай ук басымны соңгы иҗеккә кабул итеп алалар (уникѐ, бишә̀ү, сиксә̀н, егермѐ)
- Зат, тартым, кайтым алмашлыклары басымны соңгы иҗеккә кабул итәләр (синдә̀, андà, аларда̀, минекѐ, аныкы̀, үзѐм, үзѐң)

  Күрсәтү алмашлыклары басымны ике төрле кабул итәләр:
- Ә̀нә, мѐнә, а̀ндый, мо̀ндый, шу̀ндый алмашлыклары басымны беренче иҗеккә кабул итәләр
- Тегѐ, бола̀й, шула̀й,тегелә̀й алмашлыкларында басым соңгы иҗеккә төшә

  Рәвешләр басымны өч төрле кабул итәләр:
- Кайбер рәвешләрдә басым соңгы иҗеккә төшә (әкрѐн, оза̀к, соңра̀, элѐк, түбә̀н )
- Рәвешләрнең күпчелегендә басым беренче иҗеккә төшә га̀ять, һә̀рьяклап, бѐрьюлы, кө̀нозын, мә̀ңге, дә̀ррәү(дәррә̀ү), кө̀не –төне, җә̀й – кыш, а̀з – маз, ка̀т – кат, та̀у – тау
- Рәвешләрнең кайберләре сүзне оештыручы иҗек басымын "уртага" да кабул итәләр: башта̀наяк, ая̀гүрә, яла̀нбаш, тата̀рчалап

  Фигыльләрдә дә басым үзенчәлекле төсмерләргә ия:

- Юклык кушымчасы алганда гына, басым фигыльләрдә юклык кушымчасы алдындагы иҗеккә төшә (сана̀мыйм, кара̀ма, яса̀мыйм, вакла̀ма, сакла̀маган)

- Хикәя фигыльләрдә басым заман кушымчасына төшә (мин укы̀йм, син укыйсы̀ң, ул укы̀й, без укыйбы̀з, сез укыйсы̀з, алар укы̀йлар)

- Үткән һәм киләчәк заман хикәя фигыльнең III зат күплек санында басым соңгы иҗеккә төшә (сакладыла̀р, якладыла̀р, барладыла̀р, карадыла̀р, саклаячала̀р,яклаячакла̀р, барлаячакла̀р, караячакла̀р)

- Сыйфат фигыль, исем фигыль, инфинитив, хәл фигыльнең I, II, III төрләре, шарт фигыль формалары басымны соңгы иҗеккә кабул итәләр (баручы̀ апа, уку̀, биергә̀, барып̀ , бара̀ – бара̀,барга̀ч, укыса̀ )

  Беренче карашка, кагыйдәләр камил, аңлаешлы булса да, укучылар "басым" темасын авыр үзләштерәләр. Димәк, һәр дәрестә, кайсы сүз төркемен үтүгә карамастан, әлеге темага һәрдаим игътибар бирергә, кагыйдәләрне даими рәвештә кабатлап торырга кирәк. Һәрбер укучы үзенең "Кагыйдәләр дәфтәре"нә һәр кагыйдәне язып,мисаллар белән дәлилләп өйрәнсә генә, тиешле нәтиҗәләргә ирешергә мөмкин. Барлык кагыйдәләрне үзләштергәннән соң, ел азагында укучыларга тест тәкъдим итәргә мөмкин. Биремне һәр укытучы үзе үзгәртә, төзәтмәләр кертә, тулыландыра ала.

1.Билгеләү алмашлыкларында басым дөрес куелган рәтне билгелә

а) һә̀ркайсы, һә̀ммәсе,һә̀рберсе, һә̀ркайда

б) һәрка̀йсы, һәммә̀се, һәрбѐрсе, һәрка̀йда

в) һəркайсы̀, һəммəсѐ, һəрберсѐ, һəркайдà
2. Юклык кушымчасын алган фигыльлəрдə басым дөрес куелган рəтне билгелə
а) бàрмасыннар, кү̀рмəгəннəр, карашты̀рмагансың, капкалàмаган
б) бармàсыннар, күрмə̀сеннəр, караштырмàгансың, капкаламàган
в) бармасы̀ннар, күрмəсѐннəр, караштырмагàнсың, капкаламагàн
3. Исемнəрдə басым дөрес куелган рəтне күрсəт
а) абагà, алмагàч, Сөмбелə̀, каракалпàк
б) Кàзан, башкàла, Нə̀симə, тө̀нбоек
в) коры̀лык, тàрак, шəһ̀əр, карамà
4. II зат боерык фигыльлəрдə басым дөрес куелган рəтне билгелə
а) уты̀р, сѝкер, кайгы̀рт, саклà
б) вàкла, саклà, сàйра, сорà
в) бàргала, сòра, у̀тырыгыз
5. Хəбəрлек кушымчасын алган исемнəрдəге басымны дөрес билгелə
а) у̀кучымын, табѝбсың, ты̀лсымчысың
б) төзүчѐмен, сатучы̀сың, пешекчѐмен
в) дөрес җавап юк
6. Рəвешлəрдə басым дөрес куелган рəтне билгелə
а) татàрча, марѝча, минѐмчə, башкòртча
б) тàтарча, мàрича, мѝнемчə, бàшкортча
в) дөрес җавап юк
7. Рəвешлəрдəн генə торган һəм басым дөрес куелган рəтне билгелə
а) мату̀р, àюдай, бү̀рѐдəй, əтѝдəй
б) ѝкенче, күбəлə̀ктəй, барàлар, тизлѐк
в) төлкѐдəй, бурсы̀ктай, карлыгàчтай
8. Сорау алмашлыкларыннан торган һəм басым дөрес төшкəн рəтне билгелə
а) кѐмнəр, кàйда, кàйчан, нѝлəр
б) һѝчкем, һə̀ммə, мòндый, шу̀лар
в) шу̀нда, шакты̀й,бишə̀ү, биштə̀р
9. Əлбəттə, лəкин, һəммə сүзлəрендə басым...... иҗеккə төшə
а) икенче,беренче,беренче
б) беренче, беренче, икенче
в) дөрес җавап юк
10. Сыйфатлар алдыннан килгəн көчəйткеч кисəкчəлəргə басым
а) төшə
б) төшми
в) дөрес җавап юк
11. Рəвешлəр алдыннан килгəн кисəкчəлəргə басым
а) дөрес җавап юк
б) төшə
в) төшми
12. Парлы сүзлəрдə басым еш кына ...... өлешкə төшə
а) дөрес җавап юк
б) икенче

в) беренче

13. Исемнәрдә басым төшкән иҗекнең санын әйт

Кыр - мыс - ка, чи – керт – кә, үр –мә - куч, кү – бә –ләк

а) барлык сүзләрдә дә икенче иҗеккә төшә

б) барлык сүзләрдә дә соңгы иҗеккә төшә

в) барлык сүзләрдә дә беренче иҗеккә төшә

14. Басым дөрес төшкән сүзләрдән торган рәтне билгелә

а) ашамлы̀к, кабартма̀, карлыга̀ч, карлыга̀н

б) куркы̀ныч, каенна̀р, ка̀рмак, бөркѐт

б) кѐрфек, бөртѐк, ба̀шак, ка̀рак

15.Басым дөрес төшкән һәм сыйфатлардан гына торган рәтне билгелә

а) куркы̀ныч, салкы̀н, са̀ры, сабы̀р

б) сыбызгы̀, көчлѐ, ка̀лын, бѝек

в) ямьлѐ, назлы̀, ела̀к, ера̀к

16.Саннардан торган һәм басым дөрес төшкән рәтне билгелә

а) икә̀ү, бѐренче, йө̀зләп, а̀лты

б) саннарга басым төшми

в) алтмышынчы̀, сигѐз, тукса̀н, бишлә̀п

17. Рәвешләргә басым дөрес төшкән рәтне билгелә

а) югары̀, тү̀бән, тѝзрәк, тайгы̀ч

б) тиздә̀н, тирәнтѐн, җәяү̀, минѐмчә

в) рәвешләргә басым төшми

Сүз басымын дөрес кую күнекмәләрен үзләштерүдә татар теле дәресләрендә фонетик анализның роле зур. Рус мәктәбе шартларында фонетик анализ өчен дә сәгатьләр саны җитәрлек түгел. Фонетик анализны ясау тәртибен иң төгәл һәм эзлекле итеп сурәтләнгән хезмәт итеп, Ч.М.Харисованың “Татар теле. Анализ үрнәкләре” (“Мәгариф” нәшрияты, 2009.) хезмәтен саныйм. Әлеге методик хезмәттә һәр сүз төркеменә фонетик анализ ясау тәртибе укучылар өчен аңлаешлы, төгәл итеп бирелүе белән отышлы, сүз басымын кабатлау өчен күнегүләр дә җитәрлек.

Шулай ук Н.В.Максимовның “Урта мәктәптә татар теле укыту. Фонетика. Морфология” китабында да укучы, укытучы өчен терәк булырдай анализ үрнәкләре күп. Һәр ике дәреслек тә мәктәп укытучысының өстәл дәреслеге булырга лаеклы хезмәтләр. Моннан тыш, шәһәр, җөмһүрият күләмендә үткәрелүче олимпиадаларга, имтиханнарга, БДИга хәзерләнгәндә дә, әлеге чыганаклардан файдалану үзен аклый.

“Сүз басымы”темасына таратма материал, күрсәтмә әсбаплар туплау эшенә укучыларның үзләрен дә җәлеп итәм.”Ялкын”, “Сабантуй”, “Көмеш кыңгырау”, “Чистай хәбәрләре”, “Мәгърифәт”, “Мәгариф” кебек саллы газета - журналлардан тупланган мәкаләләр, хикәяләр, шигырьләрдән төрле мисаллар алып, сүз басымының куелышын тикшерәбез.Укучыларны берничә төркемгә бүлеп, һәр төркемгә бер төрле бирем тәкъдим итәм,

уйлау һәм фикер йөртү, гамәли эш өчен бераз вакыт бирәм. Һәр төркемнең үз дәлилләре тыңланганнан соң, дөрес фикер табыла, нәтиҗәләр ясала.

Биремнәрне бераз катлауландырып бирү дә үзен аклый, укучылар сүз төркемнәрен кабат искә төшерәләр, сүз төркемнәрендә басымның төрле урында куелуына төшенәләр.Мәсәлән,бирелгән сүзләрнең кайсы сүз төркеменә керүен билгелә, басымнарын куй, нәтиҗә яса!
(Кѐмдер – билгесезлек алмашлыгы, басым беренче иҗеккә төшә.)
Кемдер, кайдадыр, ниндидер, ничәдер, күпмедер,ниләрдер, татарча, башкортча, украинча, казахча, төлкедәй, бүредәй, лачындай, укучымын, табибсың, төзүчедер, сөйләмә, сайрама, бакылдама, тыпырдама, караган, сөйли торган (кеше), укучы (бала), барып (кайту), күреп (сөйләшү), уйлый – уйлый( төзү), алгач (карау), сөйләшкәнче (аңлау) .
1.Бирелгән сүзләрне, басым билгесе куеп, күчереп языгыз һәм аларның нинди сүз төркеменә каравын җәяләр эчендә күрсәтегез: салмȁ (исем – ризык), сȁлма ( боерык фигыль).
Карама – карама, басма – басма, кабат – кабат, алма – алма, уран – уран, ярма – ярма, Бөгелмә – бөгелмә, бүлмә –бүлмә, ныгытма – ныгытма, казы – казы.
2. Бирелгән сүзләрнең ахырына бер яки берничә хәреф яки бер иҗек өстәп яңа сүзләр яса, һәр сүзнең басымны билгелә.
Кар...., ка..., бөтен..., бар..., койма., шәм..., шик..., төс..., там..., күл..., ирек...,балык..., бака..., чәч.., каш..., таш..., төс..., тап..., кап..., сап..., сөй.., сөйкем..., сап..., сабак..., алма..., акча..., арка..., там....
3. Мәкальләрне укы һәр мөстәкыйль сүз төркеменә ( исемнәргә, саннарга, фигыльләргә, рәвешләргә, сыйфатларга, алмашлыкларга) басымны куй.
Авыз күрке – тел, тел күрке – сүз.
Уйламый сөйләсәң, авырмый үләрсең.
Бауның озыны, сүзнең кыскасы яхшы.
Ике уйла, бер сөйлә.
Аз сүз – татлы, күп сүз – буш.
Күп сүзнең - эзе яхшы, әз сүзнең үзе яхшы.
Сүзнең башыннан элек ахырын уйла.
Телгә игътибарсыз – илгә игътибарсыз.
Телең белән тегермән корма, аннан барыбер он чыкмас.
Галим барда телең тый, оста барда телең тый.
Сөйдергән дә тел, биздергән дә тел.
Каты сүздән тал сына, йомшак сүзгә таш та эри.
Яхшы сүз җанга рәхәт, яман сүз җанга җәрәхәт.
Авыздагы сүзгә син ия, авыздан чыккач – сүз ия.

Моннан тыш, әдәбият дәресләрен татар теле дәресләре белән бәйләп алып бару да (фәнара бәйләнеш) тиешле нәтиҗәләр бирә. Һәр өйрәнелгән тема яки аерым әсәрләрдән алынган өзекләр ярдәмендә төрле сүз төркемнәрендәге басымны дөрес итеп кую күнекмәләрен ныгытырга

мөмкин. Гамәли эш укучылар күңеленә хуш килә. Алар төркемнәрдә дә, аерым да, группалап та эшләргә өйрәнәләр. Укытучы эш төрләрен үзе сайлый, аларны төрләндерә, гадидән катлауландыра бара. Мәсәлән:
а) Аптырадыгызмы минем
Кулымда зонтик күреп?
Фасылларны бутаган дип,
Йөрисез бугай көлеп.
(Йолдыз, “Яңа зонтик”)
б) Усал да түгел үзе,
Тик куркыта һәммәсен.
Әби каршына чыкса,
Ул укый ләхәүләсен.
Безнең кара песи бар,
Төн кебек ул, чем – кара.
Юлыңны йөгереп чыксамы,
Бар, курыкмыйча кара!
(Йолдыз, “Кара песи”)
в) Әби берни күрмәде,
Әби берни белмәде.
Сандык бит тора тышта.
Үпкәм зур чынлап кышка.
Китсә китә белмәде,
Шундый суык көннәре.
Бик тә саран, үз урынын
Матур язга бирмәде.
(Йолдыз, “Кыш үпкәсе”)
г) Адәм заты хөсетлеккә чумган,
Мәгънәсезлек – кая карама.
Гаделсезлек дигән зәһәр уклар
Йөрәгемә килеп кадала.
(Ф.Тарханова, “Хөсетлек”)
д) Татарлыгын итми калса татар,
Татар булмам, диеп уйлыйдыр.
Күтәрелеп килгән милләттәшен
Түбәсенә төеп кыйныйдыр.
Башка милләт андый түгел ләса,
Никтер безгә фетнә чәчелгән.
Әнә кайберәүләр берсен – берсе
Үстерәләр тартып чәченнән.
Безнеке ни: көнчелектән яна,
Берәү аны уза башласа,
Эттән алып, эткә салып сүгә,
Хөсетлектән күзен кан баса.
(Ф.Тарханова, “Татарлык”)
е) Җигеп атын, майлап күчәрләрен,

Күктән йолдыз төяп төшәрләрем,
Сүзен атып, корыч тишәрләрем –
Болар бар да минем мишәрләрем.
Җебегән белән дөнья исәрләрен
Бергә җыеп аркан ишәрләрем,
Эш – гамәлдә янып – пешәрләрем
Барысы да минем мишәрләрем.
Гамьсезләрнең ярты исәннәрен
Теле белән тотып кисәрләрем,
Бер – берсенә карап үсәрләрем –
Бар да, канәт, минем мишәрләрем.

(Ф.Тарханова "Мишәрләрем")

Дөнья ап – ак, күңел хуш,
Сагындырган икән, кыш.
Тәрәзәгә күзең сал,
Тәүге карны күреп кал.
Карлар төшә серләшеп,
Безгә шатлык өләшеп.
Үтә гомер шул карларның
Пакьлегеннән көнләшеп.

(С.Әхмәтҗанова "Тәүге кар")

Кырауга биреште көз яме,
Кышларга тапшырды язмышын.
Җирләрнең куйнына баш салып,
Көз ала ахыргы сулышын.
Көзләрнең гомере бер түгел,
Китәр дә кайтыр ул әйләнеп.
Безләрнең язмышы торгак күк,
Пәрәвез җебенә бәйләнеп.

(С.Әхмәтҗанова "Көз һәм без")

Сабый чактагыдай, иркәләнеп,
Алларыңа башым салыймчы?
Үзем күптән әни булсам да мин,
Нәни кызың булып калыймчы?
Чәчләремнән сыйпа әле, әнкәй,
Тойыйм кулларыңның җылысын.
Изге йөрәгеңә сыйдыргансың
Мәхәббәтнең иң – иң олысын.

(С.Әхмәтҗанова "Әнкәем – сердәшемә").

Укучыларның җәйге ялларында да, өй эше итеп, җирле сөйләм үрнәкләрен туплау, магнитофон тасмасына яздыру эшен бирергә мөмкин. Монда инде укучылар өчен җиң сызганып эшләрлек мәгълүмат туплана! Көнбатыш диалекты вәкилләре буларак, җирле сөйләмдә сүз басымын куюда төрле – төрле хаталар очрый.Укучылар белән бергәләп әлеге

язмалар тыңлана, хаталар төзәтелә,кагыйдәләр искә төшерелә, нәтиҗәләр ясала.

Мәктәптә оештырылган “Туган тел” түгәрәгендә дә “ Сүз басымы” темасын гамәли куллану күнегүләре өчен җирлек тудырырга мөмкин. Түгәрәк кысаларында мин Г.Тукай иҗатын тирәнтен өйрәнүгә багышланган “Өч наданга алмашынмас, бер язу белгән кеше...”дигән авторлык программасын кулланып эшлим. Идея – эстетик анализ, шигырь төзелешен тикшерү белән беррәттән, һәр шигырьдә,поэмда басымның ролен билгелибез, нәтиҗәләр чыгарабыз. Шул рәвешле, Г.Тукайның 40 тан артык әсәрен анализлап чыгабыз.Ә кайбер укучыларга “Г.Тукай иҗатында просодик чаралар” темасына чыгышлар да тәкъдим итәм.Иң уңышлы дип табылганнарын шәһәр күләмендә үткәрелүче фәнни – гамәли конференциягә чыгарам. Шул рәвешле, Г.Тукайның “Су анасы”, “Шүрәле”, “Исемдә калганнар”; Н.Әхмәдинең “Чалбар”, А.Гыйләҗевның “Өч аршын җир”, Ф.Садриның “Таң җиле”, Г.Исхакыйның “Ул әле өйләнмәгән иде” әсәрләрендә просодик чаралар темасына фәнни –гамәли эшләр шәһәр, республика күләмендә үткәрелгән ФГК да I, II урыннарны яуладылар.

Димәк, мәктәп, шәһәр, җөмһүрият күләмендә үткәрелгән ФГК ләрдә дә просодик чараларны анализлаганда, “Сүз басымы” темасына аеруча игътибар итәргә тырышам. Укучылар белән бергәләп, әсәрләрдәге барлык сүз төркемнәрендәге басымны билгеләп чыкканнан соң, Excel программасында төрле сүз төркемнәрендәге басымнарны графикка урнаштырабыз. Сүз төркемнәрен төрле төсләр белән билгелибез, эшнең нәтиҗәсе күренгәч, укучыларымның эшкә теләкләре тагын да арта, белемнәре тирәнәя.

Шулай ук Интернет ресурсларын да эшкә җигәбез, классикларыбызның төрле жанрларга караган әсәрләрен тыңлап, басымның куелышын анализлыйбыз.

Димәк, “Сүз басымы” темасын гамәли өйрәнү өчен эш төрләре күп, шулар арасыннан максатка ярашлысын, нәтиҗә бирердәйләрен сайлап ала белеп, дөрес итеп куллана гына белергә кирәк.

Кулланылган әдәбият:


1. Ф.С.Сафиуллина.Тел гыйлеменә кереш. Казан:ТаРИХ “Нәшер”, 2001.
2. А.Х.Хайруллина. Дөрес сөйләшегез. Казан:” Казан” нәшрияты, 1992.
3. Р.С.Абдуллина, Г.М.Шәйхиева. Татар теле ( 10 сыйныф өчен дәреслек). Казан: Мәгариф, 2006.
4. Р.Ә.Асылгәрәева, М.З.Зиннатуллина .Татар теле (7 сыйныф өчен дәреслек) Казан: Мәгариф, 2010.
5. Ф.Ф.Харисов, Ч.М.Харисова. (Татар теле ) 5 сыйныф өчен дәреслек) Казан: Мәгариф, 2004.
6. Й.Җамалетдинова . Антенналы бәрәңге. Казан: ТКН, 1994.
7. С.Әхмәтҗанова . Оч иреккә, җырым! Казан: Идел – Пресс, 2002.
8. Ф.Тарханова. Йөрәгемә яшерелгән серләр. Казан: ТКН, 2001.
9. Н.В.Максимов. Урта мәктәптә татар теле укыту. Фонетика. Морфология. Казан: Мәгариф, 2004.
10. Ф.С.Сафиуллина, Г.Б.Ибраһимов. Хикмәтле дә, бизәкле дә, Туган тел. Казан: Мәгариф, 1998.
11. Ф.С.Сафиуллина, М.З.Зәкиев. Хәзерге татар теле. Казан: Мәгариф, 2002.
12. Ч.М.Харисова .Анализ үрнәкләре. Казан: Мәгариф, 2010.